**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2021елның 27 сентябре 2806 номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләү турында

Территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең, юридик затларның һәм гавами-хокукый берәмлекләрнең мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24, 25 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9, 10 статьяларына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, карар бирәм:

1. Түбәндәге составта Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләүгә керешергә:

1) территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;

2) җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын урнаштыруны планлаштыру картасы;

3) җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре картасы;

4) җирлекнең функциональ зоналары картасы.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләү 100% күләмендә инвестор акчалары исәбеннән башкарылачак, башкарылган эшләр өчен түләү шартнамә шартлары нигезендә гамәлгә ашырылачак дип билгеләргә.

3. Генераль план проектын әзерләү эшләренең түбәндәге этапларын билгеләргә:

| Этап номеры | Эш этаплары исеме |
|---|---|
| 1 | Генераль план проектын әзерләүгә контракт төзү, техник бирем әзерләү |
| 2 | Генераль план проектын әзерләү |
| 3 | Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар (фикер алышулар) үткәрү (шул исәптән гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм аларның нәтиҗәләре турында бәяләмә) |
| 4 | Генераль план проектына гавами тыңлаулар (фикер алышулар) нәтиҗәләре буенча төзәтмәләр кертергә кирәк булганда |
| 5 | Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында генераль план проектын килештерү |

| | |
|---|---|
| 6 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының генераль план проектын, гавами тыңлаулар (фикер алышулар) нәтиҗәләре турында бәяләмә, аны раслау өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә. |

4. Генераль план проектын әзерләү эшләрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.А.Новиков**